МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.04.2019 г.Казань № 221

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 23 апрелендә 5530 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 31.07.2015 № 533, 06.06.2016 № 316, 28.11.2016 № 668, 29.03.2017 № 194, 08.06.2017 № 349, 22.12.2017 № 895, 07.05.2018 № 351, 18.09.2018 № 885 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.04.2019 г. №221 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 643 номерлы боерыгы белән расланган Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлекнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәтен алучы булып җан башына исәпләгәндә уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм мөлкәти тәэмин ителү дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән дәрәҗәдән кимрәк булган гаиләләрдә туган, уллыкка алынган, опекага (химаячелеккә) алынган 16 яшькәчә балаларның (гомумбелем оешмаларында укучыларга – алар укуын тәмамлаганчыга кадәр, ләкин гомумбелем оешмасын тәмамлаганнан соң ике айдан да артыграк түгел һәм балага 18 яшь тулганчы гына) даими яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча бергә яшәүче ата-аналарның (законлы вәкил) берсе тора.»;

2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.5 пунктның кырык тугызынчы абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы буенча да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Яшел Үзән шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша да җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

гаилә әгъзаларында күчемсез мөлкәт булуы турында белешмәләр (Росреестрда);

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында белешмәләр (халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте учреждениеләрендә);

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә айлык матди тәэминатларның күләмнәре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (вәкаләтле органнарда);

Россия ЭЭМ түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия ЭЭМ);

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында белешмәләр (Россия Оборона министрлыгында);

социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие күләме турында белешмәләр (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләме турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);

социаль яклау органнары билгели һәм түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан билгеләнә һәм түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында белешмәләр, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарында);

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә яшәү урыны (вакытлыча тору урыны) буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);

опека (химаячелек) билгеләү турында, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, опекунның (химаяченең) баланы асраган өчен ала торган акча күләме һәм тәрбиягә алган ата-аналарга тиешле бүләкләү суммалары турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);

уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында белешмәләр (гомуми белем бирү оешмасыннан).

Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Аталган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне

күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

3 бүлектә:

3.4 пунктның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, вәкаләтле органнардан;

эшсезлек буенча пособие күләме, матди ярдәм һәм эшсез гражданнарга башка төрле түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы нигезендә һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм түләүләре турында – халыкны эш белән тәэмин итүнең дәүләт хезмәте учреждениеләреннән;

пенсионерларга Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган пенсияләрнең, компенсация түләүләренең һәм өстәмә рәвештә ай саен түләнә торган

матди тәэминатларның алынуы һәм күләмнәре турында, Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләмнәре турында;

социаль яклау органнарыннан йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында;

социаль яклау органнарыннан социаль яклау органнары тарафыннан бала караган өчен түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарыннан;

социаль яклау органнары билгели һәм түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында, социаль яклау органнарыннан;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан билгеләнә һәм түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында, социаль яклау органнарыннан;

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча теркәлгән гражданнар турында, вәкаләтле органнардан.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган белешмәләр.

3.4.2. Балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

2013 елның 23 октябреннән соң туган балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында, туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта, – вәкаләтле органга;

Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында;

опека (химаяче) билгеләү турында, баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында, опекунның (химаяченең) баланы асраган өчен ала торган акча күләме һәм тәрбиягә алган ата-наларга тиешле бүләкләү суммалары турында (җирле үзидарә органнарына);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр, – җирле үзидарә органнарына;

дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча теркәлгән гражданнар турында – вәкаләтле органнарга;

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе

бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса, – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтле булмау буенча пособие, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие, шулай ук медицина учреждениеләрендә йөклелекнең башлангыч срокларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

бала караган өчен айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

физик зат файдасына эшкә яллаучы (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (вәкаләтле органга);

Россия ЭЭМ түләнә торган пенсия күләме турында (Россия ЭЭМ);

гариза тапшыручының паспорты чын булуын раслау турында, әгәр гариза Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән булса – Татарстан Республкиасы буенча Эчке эшләр министрлыгына;

уналты яшьтән олырак булган баланың (балаларның) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмасында белем алуы турында, – гомумбелем бирү оешмаларына;

гаилә әгъзаларында күчемсез мөлкәт булуы турында – Росреестрга;

билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын турында – җирле үзидарә органнарына;

гаилә әгъзаларында транспорт чараларының булуы турында – вәкаләтле органнарга.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамә.»;

3.6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) балага пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) хәбәр итә.»;

3.8 пунктта:

3.8.1 пунктчаның дүртенче абзацында «Идарә (бүлек) җитәкчесенә» сүзләрен «Үзәк бүлеге җитәкчесенә» сүзләре белән алмаштырырга;

3.8.3 пунктчаның беренче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. «Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (язмача формада почта адресы буенча, электрон формада электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр юллап, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) балага пособие билгеләү турында

(билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында хәбәр итә.»;

4 бүлектә 4.2 пунктның икенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

5 бүлекнең 5.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә
_____________________________________________
_____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____
«__» __________ 20__ ел.

Мин, ______________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:
_____________________________________________________________________________
(индексын күрсәтеп мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
_____________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте алучы мәнфәгатьләрендә эш итүен раслаучы документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Снилс (алучыныкы) __________

Түбәндәгене билгеләүне сорыйм ________________________________________,

(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының почта адресы, яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

______________________________________________________________

(дәүләт хезмәте алучының шәхесен таныклаучы документ реквизитлары)

______________________________________________________________

Балага айлык пособие ____________________________________________

(баланың тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Дәүләт хезмәтен алучыда һәм аның гаилә әгъзаларында милектә мөлкәт булуы турында белешмәләр*:

1. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы һәр гаилә әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып китә торган торак урын (торак урынның бер өлеше), ☐ бар ☐ юк

шул исәптән:

1.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, мондый чир булганда законнарга ярашлы рәвештә аның белән бергә яшәве мөмкин булмаган хроник чирләүнең катлаулы формасыннан интегүче гаилә әгъзасы биләгән торак урын мәйданы (шул исәптән фатирда аерым изоляцияләнгән торак урын мәйданы); ☐ бар ☐ юк ☐ мәйданын күрсәтергә

1.2. билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын. ☐ бар ☐

юк

2. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, суммар мәйданы ялгыз яшәүче гражданинга исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып китә торган, ә ике һәм аннан күбрәк кешеле гаиләгә исәпләгәндә һәр гаилә әгъзасына 23 квадрат метрдан артып китә торган ике һәм аннан күбрәк торак урын (торак урын өлешләре), ☐ бар ☐ юк

шул исәптән:

2.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, мондый чир булганда законнарга ярашлы рәвештә аның белән бергә яшәве мөмкин булмаган хроник чирләүнең катлаулы формасыннан интегүче гаилә әгъзасы билгән торак урын мәйданы (шул исәптән фатирда аерым изоляцияләнгән торак урын мәйданы); ☐ бар ☐ юк ☐ мәйданын күрсәтергә

2.2. билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын. ☐ бар ☐ юк

3. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һәм торак урын булып тормаган биналар, төзелмәләр, корылмалар (бина, корылма, төзелмә өлешләре) (индивидуаль торак төзелеше, ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан транспорт чаралары (гараж, машина урыны), хуҗалык корылмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектларыннан һәм әлеге кушымтаның 4 пунктында саналган объектлардан тыш); ☐ бар ☐ юк

4. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, хуҗалык корылмалары булып тормаган, бер гаилә әгъзасына исәпләгәндә суммар мәйданы 40 квадрат метрдан артып китә торган бер яки берничә бакча йорты, дача (бакча) төзелеше объектлары; ☐ бар ☐ юк

5. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы (суммар мәйданы) бер гаилә әгъзасына исәпләгәндә 0,2 гектардан артып китә торган бер яки берничә җир кишәрлеге; ☐ бар ☐ юк

6. Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән автомобиль, автобус, үзйөрешле машина, пневматик һәм чылбырлы йөрешле механизм, самолет, вертолет, теплоход, яхта, паруслы судно, катер, кар чанасы, моточана, гидроцикл, үзйөрешле булмаган тагып тарттырыла торган судно, башка төрле су һәм һава транспорт чарасы (дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаилә тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән һәм утыру өчен биштән артык урыны булган автомобильдән тыш);

☐ бар ☐ юк

7. мөрәҗәгать иткән көнгә икесенең берсенең чыгарылу елы өч елдан артып китмәгән ике һәм аннан күбрәк җиңел автомобиль (инвалидка куллану өчен махсус җиһазландырылган җиңел автомобильдән, утыру өчен биштән артык урыны булган һәм дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаилә тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән тыш).

☐ бар ☐ юк

* мөлкәтнең булуы «V» тамгасы белән билгеләнә;
мөлкәтнең булмавы «X» тамгасы белән билгеләнә.

Түләү алучының гаилә составы:

| № | Ф.И.А. (туу датасы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәклесен билгеләргә ** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |
| 3 | | | | |
| 4 | | | | |

** дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар күрсәтелә

Раслыйм: гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы, шулай ук ________________________________________ карата
(дәүләт хезмәте алучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителмәгән, ата-аналык хокукында чикләнмәгән.

__________ ______________________________
(имза, тулы имза)

_____________________________________________________________________________
(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Уналты яшьтән өлкәнрәк бала (балалар) укый:

_________________________________ ______________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, ата исеме) (гомумбелем оешмасының исеме)

_________________________________ ______________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, ата исеме) (гомумбелем оешмасының исеме)

Билгеләнгән түләүләрне күчерергә:
счет реквизитлары_________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә банкта яисә башка төрле кредит учреждениесендә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге реквизитлары _________________________________________________
(дәүләт хезмәтен алучының яисә аның законлы вәкиленең почтадан җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең төгәл булуы, шулай ук аларны үз эченә алган документларның хаклыгы өчен җаваплы булам ________________________________
(гариза бирүченең имзасы)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза.

_____________________ почта адресына язмача формада
(почта адресы)

______________________ телефонына смс-хәбәр юллап
(телефон номеры)

_________________ электрон почта адресына электрон документ формасында
(электрон почта адресы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша

_____________________
(гариза бирүченең имзасы)

Эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан минем файдага түләнгән түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр суммасы турында Россия Федерациясе Пенсия фондында социаль ярдәм чаралары билгеләү буенча мөрәҗәгать итү аеннан алда килүче соңгы 6 ай һәм 12 ай өчен булган белешмәләр нигезендә балага айлык пособие билгеләүгә, шул исәптән яңа чорга автомат рәвештә билгеләүгә, риза.

_____________________________________
(гариза бирүченең имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде _________ __________ ___________________
(дата, белгеч имзасы, тулы имзасы)

---

Өзү линиясе

Язу-белдерүнамә

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте__________ _________ ______________________ ____________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта

БАЛАГА АЙЛЫК ПОСОБИЕ БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРҮДӘ ТОТУ ҺӘМ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

1. БАЛАГА АЙ САЕН ТҮЛӘНӘ ТОРГАН ПОСОБИЕ БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР

1.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»

1.2. дәүләт казна учреждениесе бүлекләре

| Бүлекнең аталышы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең «Чаллы» шәһәр округындагы № 1 бүлеге | (8552)<br>47-46-53<br>47-46-54 | 423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6, №1 подъезд;<br>423823, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Кояшлы бульвар, 6, №1 подъезд;<br>chl.1@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең «Чаллы» шәһәр округындагы № 2 бүлеге | (8552)<br>71-47-02<br>71-49-39<br>71-80-35 | 423850, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Гидротөзүчеләр ур., 14 й.<br>chl.2@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әгерҗе муниципаль районындагы № 2 бүлеге | (85551)<br>2-42-33<br>2-28-32 | 422230, Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Карл Маркс ур., 11А й.<br>agr.2@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Азнакай муниципаль районындагы № 3 бүлеге | (85592)<br>7-25-93<br>7-13-99 | 423330, Татарстан Республикасы, Азнакай ш., Болгар ур., 9/2 й.<br>azn.3@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Аксубай муниципаль районындагы № 4 бүлеге | (84344)<br>2-92-76 | 423060, Татарстан Республикасы, Аксубай ш.т.п., Совет ур., 4<br>aks.4@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Актаныш муниципаль районындагы № 5 бүлеге | (85552)<br>3-22-97<br>3-22-96 | 423740, Татарстан Республикасы, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й. akt.5@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Алексеевск муниципаль районындагы № 6 бүлеге | (84341)<br>2-37-73<br>2-53-01<br>2-32-75 | 422900, Татарстан Республикасы, Алексеевск ш.т.п., Казаков ур., 8 й.<br>ale.6@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әлки муниципаль районындагы № 7 бүлеге | (84346)<br>2-08-94 | 422870, Татарстан Республикасы, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9<br>alk.7@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әлмәт муниципаль районындагы № 8 бүлеге | (8553)<br>43-81-96<br>32-45-48<br>32-45-47 | 423452, Татарстан Республикасы, Әлмәт ш., Клара Цеткин ур., 54а<br>alm.8@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Апас муниципаль районындагы № 9 бүлеге | (84376)<br>2-10-98 | 422350, Татарстан Республикасы, Апас ш.т.п., Шоссе ур., 5 й.<br>apa.9@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Арча муниципаль районындагы № 10 бүлеге | (84366)<br>3-13-30<br>3-13-34 | 422000, Татарстан Республикасы, Арча ш., Банк ур. 6в й.<br>ars.10@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Әтнә муниципаль районындагы | (84369)<br>2-16-55 | 422750, Татарстан Республикасы, Олы Әтнә ав., |

| | | |
|---|---|---|
| № 11 бүлеге | 2-16-53 | Октябрь ур., 9 й.<br>atn.11@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Баулы муниципаль районындагы № 12 бүлеге | (85569)<br>5-67-22<br>5-64-42 | 423930, Татарстан Республикасы, Баулы ш., Җинү м., 4 й.<br>bav.12@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Балтач муниципаль районындагы № 13 бүлеге | (84368)<br>2-57-94<br>2-64-32<br>2-41-37 | 422250, Татарстан Республикасы, Балтач ш.т.п., Һади Такташ ур., 3а й.<br>bal.13@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Бөгелмә муниципаль районындагы № 14 бүлеге | (85594)<br>5-00-56<br>5-02-77<br>5-02-50 | 423239, Татарстан Республикасы, Бөгелмә ш., Стрелочная ур., 1<br>bug.14@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Буа муниципаль районындагы № 15 бүлеге | (84374)<br>3-16-89<br>3-17-03<br>3-41-80 | 422430, Татарстан Республикасы, Буа ш., Ленин ур., 52 й.<br>bui.15@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Югары Ослан муниципаль районындагы № 16 бүлеге | (84379)<br>2-13-01 | 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 21а<br>usl.16@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Биектау муниципаль районындагы № 17 бүлеге | (84365)<br>7-47-80<br>4-47-99 | 422700, Татарстан Республикасы, Биектау ст., Школьная ур., 19<br>gor.17@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чүпрәле муниципаль районындагы № 18 бүлеге | (84375)<br>2-25-80<br>2-23-24 | 422470, Татарстан Республикасы, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>dro.18@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Алабуга муниципаль районындагы № 19 бүлеге | (85557)<br>7-54-53<br>7-87-82 | 423600, Татарстан Республикасы, Алабуга ш., Спас ур., 3 й. |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Зәй муниципаль районындагы № 20 бүлеге | (85558)<br>7-10-46<br>7-02-64 | 423520, Татарстан Республикасы, Зәй ш., Рәфыйков ур., 10<br>zai.20@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Яшел Үзән муниципаль районындагы № 21 бүлеге | (84371)<br>5-80-01<br>5-79-90 | 420542, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән ш., Карл Маркс ур., 57в zel.21@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кайбыч муниципаль районындагы № 22 бүлеге | (84370)<br>2-11-13<br>2-14-07 | 422330, Татарстан Республикасы, Зур Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 й. kai.22@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кама Тамагы муниципаль районындагы № 23 бүлеге | (84377)<br>2-16-84 | 422820, Татарстан Республикасы, Кама Тамагы ш.т.п., Карл Маркс ур., 2 й. kam.23@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Кукмара муниципаль районындагы № 24 бүлеге | (84364)<br>2-61-09<br>2-83-94 | 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара ш., Ворошилов ур., 44 й. kuk.24@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Лаеш муниципаль районындагы № 25 бүлеге | (84378) 2-55-82 2-44-73 | 422610, Татарстан Республикасы, Лаеш ш., Первомайская ур., 35 й. lai.25@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Лениногорск муниципаль районындагы № 26 бүлеге | (85595)<br>5-05-40<br>5-08-05<br>5-55-71<br>6-10-45 | 423258, Татарстан Республикасы, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 len.26@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Мамадыш муниципаль районындагы № 27 бүлеге | (85563)<br>3-29-82<br>3-22-83 | 422190, Татарстан Республикасы, Мамадыш ш., Совет ур., 10 mam.27@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Менделеевск муниципаль районындагы № 28 бүлеге | (85549)<br>2-19-72<br>2-02-27 | 423650, Татарстан Республикасы, Менделеевск ш., Бурмистров ур., 7а й. mnd.28@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Минзәлә муниципаль районындагы № 29 бүлеге | (85555)<br>3-18-22<br>3-10-50<br>3-33-28 | 423700, Татарстан Республикасы, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й. mnz.29@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең | (85556) | 423970, Татарстан |

| | | |
|---|---|---|
| Мөслим муниципаль районындагы № 30 бүлеге | 2-38-34<br>2-47-50 | Республикасы, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й.<br>mus.30@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы № 31 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Түбән Кама муниципаль районындагы № 31 бүлегенең өстәмә пункты | (8555)<br>45-44-92 | 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., Тынычлык пр., 60 й.<br><br>423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама муниципаль районы, Кама Аланы ш.т.п., Ильич ур., 2/01<br>niz.31@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Яңа Чишмә муниципаль районындагы № 32 бүлеге | (84348)<br>2-20-30 | 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93<br>nov.32@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Нурлат муниципаль районындагы № 33 бүлеге | (84345)<br>2-06-86<br>2-06-65 | 423040, Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Пушкин ур., 46 й.<br>nur.33@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Питрәч муниципаль районындагы № 34 бүлеге | (84367) 3-00-15<br>3-02-90 | 422770, Татарстан Республикасы, Питрәч ав., Совет ур., 20 й.<br>pes.34@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Балык Бистәсе муниципаль районындагы № 35 бүлеге | (84361)<br>2-20-98 | 442650, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе ш.т.п., Завод ур., 6а й.<br>ryb.35@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Саба муниципаль районындагы № 36 бүлеге | (84362)<br>2-28-17<br>2-28-19 | 422060, Татарстан Республикасы, Байлар Сабасы ш.т.п., Закир Йосыпов ур., 7 й.<br>sab.36@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы № 37 бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Сарман муниципаль районындагы № 37 бүлегенең өстәмә пункты | (85559)<br>2-57-32<br>2-44-05 | 423350, Татарстан Республикасы, Сарман ав., Куйбышев ур., 36 й.<br><br>423368, Татарстан Республикасы,<br>Сарман районы, Җәлил ш.т.п., Җиңүгә 30 ел ур., 13 й. |

| | | |
|---|---|---|
| | | sar.37@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Спас муниципаль районындагы № 38 бүлеге | (84347) 3-97-43 3-93-27 | 422840, Татарстан Республикасы, Болгар ш., Пионер ур., 21 й. spa.38@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Тәтеш муниципаль районындагы № 39 бүлеге | (84373) 2-62-33 2-62-39 | 422370, Татарстан Республикасы, Тәтеш ш., Ленин ур., 114 й. tet.39@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Тукай муниципаль районындагы № 40 бүлеге | (8552) 71-32-00 | 423802, Татарстан Республикасы, Чаллы ш., Есенин тыкрыгы., 1 tuk.40@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Теләче муниципаль районындагы № 41 бүлеге | (84360) 2-17-39 | 422080, Татарстан Республикасы, Теләче ав., Зур Тау ур., 5 й. tul.41@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чирмешән муниципаль районындагы № 42 бүлеге | (84396) 2-26-34 | 423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән ав., Титов ур., 26 й. chr.42@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Чистай муниципаль районындагы № 43 бүлеге | (84342) 5-33-98 5-21-60 | 422980, Татарстан Республикасы, Чистай ш., Урицкий ур., 45 chs.43@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Ютазы муниципаль районындагы № 44 бүлеге | (85593) 2-79-26 | 423950, Татарстан Республикасы, Урыссу ш.т.п., Пушкин ур., 105/1 й. uta.44@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Авиатөзелеш районындагы бүлеге | (8843) 571-63-71 570-06-41 | 420036, Татарстан Республикасы, Казан ш., Тимирязев ур., 8 avi.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Вахитов районындагы бүлеге | (8843) 238-51-35 238-41-91 | 420197, Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 10 й. vah.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлеге | (8843) 554-64-69 555-51-80 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й. |

| | | |
|---|---|---|
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Киров районындагы бүлегенең өстәмә пункты | 294-37-42 | 420078, Татарстан Республикасы, Казан ш., Ильич ур., 21/8<br>kir.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Мәскәү районындагы бүлеге | (8843)<br>554-00-65<br>554-03-45 | 420102, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.<br>mos.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Яңа Савин районындагы бүлеге | (8843)<br>523-56-08 | 420124, Татарстан Республикасы, Казан ш., Хөсәен Ямашев пр., 37 й.<br>sav.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Идел буе районындагы бүлегенең өстәмә пункты | (8843)<br>224-32-05<br>224-30-61<br>224-19-09<br>224-04-20<br>224-32-17<br><br>598-06-23 | 420110, Татарстан Республикасы, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й.<br><br>420054, Татарстан Республикасы, Казан ш., Авангард ур, 74 й.<br>pri.k@tatar.ru |
| Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы бүлеге<br><br>Республика матди ярдәм үзәгенең Казан шәһәре Совет районындагы бүлегенең өстәмә пункты | (8843)<br>272-51-79<br><br>239-63-83<br><br>263-90-60<br><br>272-51-79<br>263-90-60 | 420073, Татарстан Республикасы, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33<br><br>420075, Татарстан Республикасы, Казан ш., Совет ур., 23 й.<br><br>420100, Татарстан Республикасы, Казан ш., Галия Кайбицкая ур., 3<br><br>420140, Татарстан Республикасы, Казан ш., Җиңү Проспекты ур., 214 й.<br>sov.k@tatar.ru |

## 2. БАЛАГА АЙЛЫК ПОСОБИЕ БИЛГЕЛӘҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТҮНЕ ТИКШЕРҮДӘ ТОТУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ ОРГАННАР (УЧРЕЖДЕНИЕЛӘР) ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТЛАР

### 2.1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Директоры | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

### 2.2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

### 2.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |